СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.10.2017 ел с. Верхний Услон № 26-280

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнде, ул район Советы тарафыннан хупланды һәм гавами тыңлауларда район халкы белән фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын үтте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының 99-101 статьялары нигезендә, 2017 елның 20 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына 1нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставының яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Советының
2017 елның «30» октябреннән
№ 26-280 карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставының 6 статьясының 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (өстәмә белем бирүдән тыш, аны финанс ягыннан тәэмин итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүне оештыру), муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук каникул чорында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә балаларның сәламәтлеген һәм иминлеген тәэмин итү чараларын да кертеп гамәлгә ашыру»;

2. Уставының 7 статьясының 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итү»;

3. Уставның 15 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Район уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, район уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы конституциясе яисә законнары нигезләмәләрен әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш»;

4. Уставның 26 статьясындагы 7 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерциячел оешма идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре идарәсендә, сәяси партия катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан, федераль законнарда каралган очраклардан тыш) һәм оешма идарәсендә катнашу, җирле үзидарә органы исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырылган очраклардан тыш;

5. Уставның 26 статьясындагы 7 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) граждан, административ яисә җинаять эше буенча яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнашырга»;

6. Уставының 35 статьясынага түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Президенты Югары Ослан муниципаль районы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн - Югары Ослан муниципаль районы советына шундый гариза кергән көн»;

7. Уставның 36 статьясындагы 2 пунктында «район Советы» сүзләреннән соң «үз составыннан» сүзләрен өстәргә;

8. 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки суд карары белән сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча район башлыгы урынбасары башкара»;

9. Уставның 45 статьясындагы 7 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) юкка чыгару өлкәсендә муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра;

- террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен кабул итмәү, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эше һәм башка чаралар үткәрү юлы белән мәгълүмати-пропаганда чаралары оештыра һәм үткәрә;

- террорчылыкны профилактикалау, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү чараларында катнаша;

- муниципаль милектәге яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

- террорчылыкны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча, шулай ук аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрә;

- террорчылыкны профилактикалауда катнашу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яисә) юкка чыгаруда катнашу буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра»;

8. Уставның 50 статьясына түбәндәге эчтәлекле 2.1. пункт өстәргә:

«Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны, чит ил керемнәре һәм мөлкәтләре турында белешмәләрнең дөрес булуын тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә суд тәртибендә өзелергә мөмкин;

9. Уставның 50 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча Район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары башкара»;

10. Уставның 77 статьясындагы 10 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә;

11. Уставның 97 статьясындагы 10 пунктының 3 һәм 4 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, бүлекчәләре буенча бүлү;

- Район бюджеты чыгымнарының чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, бүлекчәләр, бүлекчәләр һәм максатчан маддәләр (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), район бюджеты чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча ведомство структурасы»;

12. Уставның 97 статьясының 12 пунктындагы 7 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- елның 1 гыйнварына, чираттагы финанс елы (чираттагы финанс елы һәм план чорының елдан-ел) артыннан килүче муниципаль эчке бурычның югары чиге»;

13. Уставның 97 статьсының 12 пунктының 10 абзацында «Районның вәкиллекле органнары тарафыннан төзелгән муниципаль финанс контроле органнары» сүзләрен «тышкы муниципаль финанс контроле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

14. Уставның 105 статьясындагы 3 пунктының икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның шул хакта фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми»;

15. Уставның 106 статьясындагы 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Район Башлыгы район Советы рәисе вәкаләтләрен башкарса, район Башлыгы тавышы район Уставын, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткәндә район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына»;

16. Уставның 107 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 пунктлар өстәргә:

«5. Район уставын федераль канунга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль

законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, Район уставын федераль законга, Татарстан Республикасы субъекты законына туры китерү срогы тиешле федераль законның, Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын, муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм гавами тыңлауларда район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында фикер алышу, гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу, район Советы утырышларының чиратлылыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм алты айдан артмаска тиеш.

6. Район уставына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (район уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау вәкаләтләре, вәкаләтләре чоры, тәртибе үзгәрү очракларыннан тыш) Район уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән район вәкиллекле органының вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң, ә муниципаль районның вәкиллекле органы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 3 яисә 1 өлешенең 3 өлеше нигезендә төзелгән очракта - муниципаль район башлыгының муниципаль хокукый актка кертелгән вәкаләтләре чоры тәмамланганнан соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов